**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МАЛОКИБЯКОЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Малая, 10, село Малые Кибя-Кози,
422080
тел. (факс): (884360) 56-2-49
E-mail: **Mbiz.Tul @tatar.ru**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ КИБӘХУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Кече урам, 10, Кече Кибәхуҗа авылы,
422080
тел. (факс): (884360) 56-2-49
E-mail: Mbiz.Tul @tatar.ru

ОКПО 94318079 ОГРН 1061675010451 ИНН/КПП 1619004429/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 20** **21 октябрь 2021 год**

Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 1 нче мартындагы 4 че номерлы «Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында”гы Федераль закон нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 1 нче мартындагы 4 че номерлы «Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге территориясендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1. Теләче муниципаль районы Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү тәртибе турында Нигезләмәгә:

1) 2 бүлектә:

А) 2.3 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга һәм хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү» сүзләренә алмаштырырга.

2. Кече Кибәхуҗа авыл җирлеге бюджетыннан беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү чыгымнарын финанслау Тәртибенә:

А) 1 пунктта «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга;

Б) 4 пунктта «шартнамәләр төзи» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыра» сүзләренә алмаштырырга, «муниципаль ихтыяҗлар өчен заказлар урнаштыру» сүзләрен «дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу» сүзләренә алмаштырырга.

3. Муниципаль оешмаларда янгын куркынычсызлыгы чаралары турында инструкцияләрнең (нигезләмәләрнең) төрләренә, эчтәлегенә һәм бәян ителешенә Төп таләпләр:

1) 2 бүлектә:

А) 2.1 пунктта «Россия Федерациясендә янгын куркынычсызлыгы Кагыйдәләрендә китерелгән (ППБ 01-03)» сүзләрен «гамәлдәге янгынга каршы нормалар белән»сүзләренә алмаштырырга.

4. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

И.Г. Заһидуллин